2023 елның «14» ноябре № 16

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 14 ноябрендә узган «2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 460 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча чишүгә юллау белән килешәсезме?- Шилангы авылы Энергетиклар урамында урам яктыртуны ремонтлау,- дигән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 17 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 12 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде, тыелып калдылар - җыенның 0 катнашучысы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылының бер өлеше территориясендә гражданнар җыены булган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 460 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча чишүгә юллау белән килешәсезме?- Шилангы авылы Энергетиклар урамында урам яктыртуны ремонтлау, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шилангы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.В.Майоров